# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясе турында

Әлеге Закон кулланучылар кооперациясе эшчәнлегенең хокукый, икътисадый һәм җәмгыяви нигезләрен билгели, аның дәүләт белән ике арадагы үзара мөнәсәбәтләр үзенчәлекләрен ачыклый, пайчыларның хокукларын һәм бурычларын, пайчыларның һәм хезмәт күрсәтелүче халыкның мәнфәгатьләрен яклауны ныгыта.

### I бүлек. Төп нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Кулланучылар кооперациясе һәм аның максатлары

1. Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясе - үзләренең икътисадый һәм җәмгыяви хәлләтләрен яхшырту максатында хуҗалык эшчәнлеген бергәләп алып бару өчен берләшкән пайчыларның ирекле җәмгыятьләре, аларның берлекләре һәм берләшмәләре җыелмасы ул.

2. Кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре үзләренең уставлары нигезендә, пайчыларның акчалата һәм матди кертемнәре исәбенә, шулай ук хуҗалык эшчәнлегеннән килә торган керемнәр исәбенә эш алып баралар.

3. Кулланучылар кооперациясе, пайчылар мәнфәгатьләреннән чыгып, хәзерләү, сәүдә, җитештерү, арадашлык эшчәнлеген һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәүче башка төр эшчән-

лекне гамәлгә ашыра, җәмгыяви-көнкүреш инфраструктурасын булдыруга һәръяклап булышлык итә, җәмгыяте хәйрия эшчәнлеге алып бара, халыкара кооперация хәрәкәтендә катнаша.

2 статья. Кулланучылар кооперациясе турында законнар

Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясе турындагы законнар әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актларыннан тора.

## II бүлек. Кулланучылар җәмгыятьләренең пайчылары

3 статья. Кулланучылар җәмгыятендә әгъзалык

1. 16 яше тулган гражданнар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары, кооперативлар, башка предприятиеләр һәм оешмалар кулланучылар җәмгыятьләренең пайчылары була алалар.

4 статья. Пайчыларның төп хокуклары һәм бурычлары

1. Пайчылар түбәндәгеләргә хокуклы:

ирекле рәвештә кулланучылар җәмгыятьләренә берләшергә, пай кертемнәрен һәм арттырылган милекнең үзенә тиешле өлешен акчалата яисә товарлар, кыйммәтле кәгазьләр рәвешендә уставларда каралган тәртиптә кире алып, бу җәмгыятьләрдән ирекле төстә чыгарга;

үз паен һәм арттырылган мөлкәтнең өлешен мирас итеп бирергә һәм бүләк итү шартнамәсе нигезендә башка берәүгә тапшырырга;

кулланучылар җәмгыятенә идарә итүдә катнашырга, башкарма-бүлү һәм тикшерү органнарына сайларга һәм сайланырга;

кулланучылар җәмгыяте әгъзалары арасында бүленергә тиешле саф табышның, пай кертеменә туры китереп, үзенә тиешле өлешен алырга;

үзенең шәхси хуҗалык һәм кәсеп продукциясен кулланучылар кооперациясе предприятиеләре аша сатканда һәм эшкәрткәндә өстенлекләрдән файдаланырга;

белгечлегенә, эшлеклелек һәм кәсби сыйфатларына карап, кулланучылар җәмгыятенә беренче чиратта эшкә алынырга;

кулланучылар җәмгыяте уставларында каралган башка хокуклардан һәм ташламалардан файдаланырга.

2. Пайчыларның хокукларын яклау Татарстан Республикасы законнарында һәм кулланучылар җәмгыятьләре уставларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Пайчылар түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

кулланучылар җәмгыяте уставын үтәргә;

кулланучылар җәмгыяте каршында аның эшчәнлегендә катнашу белән бәйле шартнамәләрне, гомуми җыелышларның, идарә итү һәм тикшерү органнарының карарларын үтәргә.

## Ш бүлек. Кулланучылар җәмгыяте, берлекләре, аларның дәүләт органнары белән үзара мөнәсәбәтләре

5 статья. Кулланучылар җәмгыяте

1. Кулланучылар җәмгыяте - пайчыларның /физик һәм /яисә/ хокукый затларның/ хокукый зат хокукларыннан файдалана торган мөстәкыйль хуҗалык оешмасы булып саналучы ирекле берләшмәсе ул. Авыл, поселок,район,шәһәр һәм башка төр кулланучылар җәмгыятьләре була.

2. Кулланучылар җәмгыяте үзләренең пайчыларының вазыйфалары өчен җавап бирмиләр, ә пайчылар үзләре керткән пай кертемнәре кысаларында гына җәмгыять вазыйфалары өчен җавап бирәләр.

3. Кулланучылар җәмгыятенең югары органы булып пайчыларның /яисә вәкилләр-нең/ гомуми җыелышы санала, ул устав кабул итә, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертә, керү һәм пай кертемнәренең күләмен билгели, кулланучылар җәмгыятенең башкарма-бүлү һәм тикшерү органнарын сайлый, аларның эшчәнлеге турында хисапларын тыңлый, аларны тотуга акчалар бүлә, берлекләр, берләшмәләр /ассоциацияләр/, акционер җәмгыятьләр, башка җәмгыятьләр һәм ширкәтләр төзү, аларга керү һәм алардан чыгу турындагы мәсьәләләрне, берлекләргә бирелә торган хокуклар турындагы, шулай ук әлеге Закон һәм җәмгыять уставы тарафыннан аның вәкаләтләренә кертелгән башка мәсьәләләрне хәл итә.

4. Әгәр пайчыларның /аларның вәкилләренең/50 процентган артыграгы пайчыларның /аларның вәкилләренең/ гомуми җыелышы карарын хуплап тавыш бирсә, карар дөрес дип санала. Пайчыларның ышанычнамәсе булганда гына вәкилләр тавыш бирүдә катнаша алалар. Кулланучылар җәмгыятьләренең башкарма-бүлү һәм тикшерү органнары пайчылар-ның /аларның вәкилләренең/ гомуми җыелышы карары буенча яшерен яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

6 статья. Кулланучылар җәмгыятьләренең берлекләре һәм аларның бурычлары

1. Кулланучылар җәмгыятьләре ирекле нигездә районнарда, шәһәрләрдә һәм тулаем республикада территория берлекләренә, шулай ук ассоциацияләргә һәм башка төр берләшмәләргә берләшә алалар, алар, үзләре керткән милекне һәм арттырылган мөлкәтнең үзләренә тиешле өлешен алып, бу берләшмәләрдән ирекле рәвештә чыгарга хаклы.

Берлеккә керү яисә аннан чыгу турында карар пайчыларның /аларның вәкилләренең/ гомуми җыелышында кабул ителә, әмма аның өчен пайчыларның /аларның вәкилләренең/ 50 процентган артыграгы хуплап тавыш бирергә тиеш.

Кулланучылар җәмгыятьләренең берлеге хокукый зат булып санала, үзләренең уставы нигезендә һәм аңа кулланучылар җәмгыятьләре /һәм аның составына кергән берлекләр/ тарафыннан бирелгән хокуклар кысаларында эш итә. Ул кулланучылар җәмгыятьләренең вазыйфалары өчен җавап бирми, ә кулланучылар җәмгыятьләре үзләре керткән кертем чикләрендә берлекләр вазыйфалары өчен җавап бирәләр.

Кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләр шартнамәгә нигезләнеп корыла.

Берлекнең югары органы булып берлеккә кергән кулланучылар кооперациясе оешмалары вәкилләренең гомуми җыелышы санала, ул устав кабул итә, башкарма һәм тикшерү органнарын сайлый, берлек эшчәнлегенә кагылышлы барлык мәсьәләләрне хәл итә. Берлекнең башкарма-бүлү, башкарма һәм тикшерү органнарының үзара мөнәсәбәтләре, бер-берсенә буйсыну мәсьәләләре устав нигезендә билгеләнә.

2. Кулланучылар җәмгыятьләренең берлекләре:

тиешле дәүләт органнарында һәм башка органнарда, шулай ук халыкара оешмаларда кулланучылар җәмгыятьләренең һәм аларның әгъзаларының мәнфәгатьләрен яктырталар һәм аларны яклыйлар, берлек уставында каралган башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыралар.

7 статья. Кулланучылар кооперациясенең дәүләт органнары белән мөнәсәбәтләре

1. Татарстан Республикасы законнарында күздә тотылган очраклардан гайре, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының кулланучылар җәмгыятьләренең, аларның берлекләренең хуҗалык-финанс һәм башка төр эшчәнлегенә тыкшынырга хаклары юк. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының кулланучылар җәмгыятьләренең,

аларның берлекләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза торган актлары буенча Татарстан Республикасының Югары арбитраж судына билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә мөмкин.

Кулланучылар җәмгыятьләренең, аларның берлекләренең хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекләренә законсыз рәвештә тыкшыну нәтиҗәсендә аларга китерелгән зыян билгеләнгән тәртиптә каплана.

2. Кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре, шулай ук алар тарафыннан төзелгән предприятиеләр һәм оешмалар аларны оештыру урыны буенча халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советлары тарафыннан дәүләт теркәлүе үткәннән соң оештырылган дип саналалар һәм хокукый зат статусы алалар.

Кулланучылар җәмгыятен теркәү өчен түбәндәге документлар бирелә: гариза, устав, пайчыларның /яки вәкилләренең/ гомуми җыелышы беркетмәсе һәм дәүләт пошлинасын түләү турындагы таныклык. Кулланучылар җәмгыятьләренең берлеген теркәү өчен түбәндәге документлар бирелә: гариза, устав, берлеккә керү яисә аны төзү турында карар кабул иткән кулланучылар җәмгыятьләре вәкилләренең җыелыш беркетмәсе.

Теркәү турындагы карар документлар бирелгәч бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Кулланучылар җәмгыятенә, кулланучылар җәмгыятьләренең берлегенә бер атна эчендә теркәлү яисә үтенечнең кире кагылуы турында хәбәр ителергә тиеш. Теркәүдән баш тарту яисә аны кире кагу буенча Татарстан Республикасының Югары арбитраж судына шикаять белдерергә мөмкин.

3. Дәүләт кулланучылар җәмгыятьләренең, аларның берлекләренең, берләшмәләренең вазыйфалары өчен җавап бирми, ә соңгылары дәүләт вазыйфалары өчен җавап бирмиләр.

4. Куллануучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә җирдән, табигый байлыклардан файдаланырга, шулай ук җир кишәрлекләре һәм табигый байлыклар сатып алырга хаклы.

5. Куллануучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык һәм статистика исәп-хисабын алып баралар.

6. Куллануучылар кооперациясе предприятиеләре һәм оешмалары арасындагы хуҗалык бәхәсләре һәм башка төр бәхәсләр, шулай ук башка хокукый затлар һәм гражданнар белән бәхәсләр билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## IУ бүлек. Куллануучылар кооперациясенең милке һәм аны хокукый яклау

8 статья. Куллануучылар кооперациясенең милке

I. Куллануучылар кооперациясе мөлкәте хосусый, күмәк /өлешле яисә уртак/ милек хокукында пайчыларныкы санала. Мөлкәтнең куллануучылар кооперациясе хезмәткәрләренә бирелә торган өлеше уставлар тарафыннан билгеләнә.

2. Куллануучылар җәмгыятьләренең мөлкәте пайчыларның кертемнәре, хуҗалык эшчәнлегеннән һәм законнарда тыелмаган башка чыганаклардан килүче керемнәр хисабына туплана.

3. Куллануучылар җәмгыятьләренең берлекләре мөлкәте аларның әгъзалары тапшырган милек хисабына, берлек предприятиеләрнең һәм оешмаларының хуҗалык эшчәнлегеннән килә торган, кыйммәтле кәгазьләр сатудан һәм башка төр эшчәнлектән керә торган чыганаклар хисабына туплана.

9 статья. Куллануучылар кооперациясе милкен хокукый саклау

Куллануучылар кооперациясе мөлкәте дәүләт тарафыннан саклана. Ул бары тик пайчылар карары нигезендә генә тартып алына,

шулай ук Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда гына гамәлдән чыгарыла ала.

## У бүлек. Кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре эшчәнлегенең икътисадый һәм җәмгыяви нигезләре

10 статья. Кулланучылар кооперациясенең эшчәнлек өлкәләре

Кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре үзләренең икътисадый һәм җәмгыяви үсеш программаларын мөстәкыйль рәвештә эшлиләр, аларны кулланучылар җәмгыятьләрендә - пайчыларның /аларның вәкилләренең/ гомуми җыелышларында, ә берлекләрдә кулланучылар җәмгыятьләре вәкилләренең җыелышларында карап тикшерәләр һәм раслыйлар.

Үзләренең уставта каралган вазыйфаларын үтәү өчен кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре хәзерләү предприятиеләре, сәүдә, җитештерү предприятиеләре һәм башка төр предприятиеләр булдыра, шулай ук банклар, иминлек җәмгыятьләре оештыра, акцияләр һәм башка төр кыйммәтле кәгазьләр чыгара һәм сата алалар. Милек аларга тулы хуҗалык итү яисә үз идарәчелегенә тапшыру хокукында беркетелә.

11 статья. Керемнәр, бәяләр кую һәм салым салу

1. Кулланучылар җәмгыятьләренең һәм аларның берлекләренең керемнәре аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә алына торган, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклардан алына торган акчалардан туплана.

Керемнәрнең мәҗбүри түләүләрдән соң калган өлешен бүлү һәм алардан файдалану тәртибе кулланучылар җәмгыятьләрендә һәм берлекләрдә аларның уставлары нигезендә билгеләнә.

2. Кулланучылар җәмгыятьләре, кулланучылар кооперациясенең предприятиеләре һәм оешмалары сатып алына торган һәм үзләрендә җитештерелә торган халык куллануы товарларына һәм продукциягә,

авыл хуҗалыгы продуктларына һәм чималына, башкарыла торган эшләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләрне мөстәкыйль рәвештә һәм шартнамәләр нигезендә билгелиләр.

3. Кулланучылар җәмгыятьләренә һәм аларның берлекләренә салым салу гамәлдәге законнар . нигезендә тормышка ашырыла.

12 статья. Хезмәт мөнәсәбәтләре һәм хезмәткә түләү

Кулланучылар кооперациясендә хезмәт мөнәсәбәтләре хезмәт турындагы законнар, әлеге Закон һәм кулланучылар җәмгыятьләренең һәм аларның берлекләренең уставлары нигезендә җайга салына.

2. Кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре вазыйфаларын үтәү өчен мөстәкыйль рәвештә хезмәткәрләр яллый алалар, эшләүчеләр санын, штатларны, хезмәтне оештыруның рәвешләрен һәм хезмәткә түләүнең күләмнәрен билгели алалар.

3. Кулланучылар җәмгыятьләрендә^ге^ һәм берлекләрдә^ге^ сайлап куела торган урыннарда эшләүче хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләре гамәлдәге хезмәт законнары һәм уставлар нигезендә җайга салына.

Кулланучылар җәмгыятенең һәм берлегенең сайлап куела торган органнарында эшләүче хезмәткәрләргә дисциплинар җәзаны /вазыйфасыннан азат итүне дә кертеп/ бары тик аларны сайлап куйган орган гына бирә ала.

13 статья. Халыкара багланышлар һәм тышкы икътисадый эшчәнлек

1. Кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре Татарстан Республикасы законнары нигезендә чит илләрдәге оешмалар һәм предприятиеләр белән халыкара багланышлар урнаштыра.

2. Кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләренең чит илләр валютасында алган табышларының дәүләткә салым түлә-

гәннән соң, башка мәҗбүри түләүләрне һәм сатуларны башкарганнан соң калган өлеше аларның үз карамакларында кала һәм алардан кире алынмый.

<u>14 статья.</u> Куллануччылар җәмгыятен, берлекне үзгәртеп оештыру һәм бетерү

1. Куллануччылар җәмгыятен үзгәртеп оештыру һәм бетерү пайчыларның /аларның вәкилләренең/ гомуми җыелышы карары яисә суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Куллануччылар җәмгыятенең эшчәнлеге туктатылган яисә ул бетерелгән очракта аның мөлкәте, салымнарны түләп бетергәннән соң, бюджет, банклар һәм башка кредиторлар каршындагы йөкләмәләрен үтәгәннән соң, пайчыларга пай кертемнәрен һәм алар өчен дивидендларны түләгәннән соң, куллануччылар җәмгыятендә булган пайчылар арасында алар тарафыннан кертелгән пай күләмендә бүленә.

2. Куллануччылар җәмгыятьләре берлеген үзгәртеп оештыру һәм бетерү куллануччылар җәмгыятьләре вәкилләренең җыелыш карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Берлек бетерелгән очракта хезмәткә түләү буенча исәп-хисап ясалганнан соң, бюджет,банклар һәм башка кредиторлар каршындагы йөкләмәләрен үтәгәннән соң калган милке берлек әгъзалары арасында бүленә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 15 июле
№1932-XII